ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Россия Федерациясе территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының, башка затларның бергәләп дин тоту һәм дин тарату максатларында төзелгән һәм законда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлгән ирекле берләшмәсе дини оешма дип танылa.”;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

“$6^1$. Гамәлгә куючыларның һәм башка юридик яисә физик затларның дини оешмалар эшчәнлегендә катнашу мәсьәләләре, дини оешма органнарын төзү тәртибе һәм аларның компетенциясе, шушы органнарның карарлар кабул итү тәртибе, шулай ук дини оешма һәм аның органнары составына керүче затлар арасында мөнәсәбәтләр дини оешмалар тарафыннан “Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә билгеләнә.”;

2) 11 статьяда түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

“5. Дини оешма төзү турындагы карарда дини оешманы төзү, аның уставын раслау, дини оешма органнарын сайлау (билгеләп кую) хакындагы белешмәләр күрсәтелә.”;

3) 19 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Дини оешмалар дәвалау-профилактика һәм хастаханә учреждениеләрендә, балалар йортларында, картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда андагы гражданнарның үтенече буенча бу максатларга администрация тарафыннан махсус бирелә торган урыннарда дини йолалар һәм тантаналар башкарырга хокуклы. Җинаять җәзасын үтәүче учреждениеләрдә дини йолалар, тантаналар һәм шәхси очрашулар Россия Федерациясенең җинаять-үтәтү законнары таләпләрен үтәгән килеш башкарыла.

Сак астында тоту урыннарындагы биналарда дини йолалар һәм тантаналар башкару Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнары таләпләрен үтәгән килеш рөхсәт ителә.

Дини йолалар һәм тантаналар мәгариф оешмалары территорияләрендә урнашкан дини билгеләнештәге биналарда, корылмаларда да, шулай ук мәгариф оешмаларының дини йолалар башкару өчен элек-электән файдаланыла торган урыннарында үткәрелергә мөмкин.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 21 июле
№ 60-ТРЗ